# Яңа көн

Балык бистәсе районы Олы Елга урта гомуми белем бирү мәктәбе

**октябрь**

## Бу санда:

- *"Укытучым - тормыш маягым"*
- *"Укытучым - якты кояшым" , "Яраткан укытучым" сочиненияларыннан өзекләр*
- *"Һөнәр сайлаганда."*

Хөрмәтле Укытучыларыбыз!
Сезне һөнәри бәйрәмегез белән чын күңелдән котлыйбыз. Авыр, әмма җаваплы һәм мактаулы эшегездә зур уңышлар, саулык-сәламәтлек, бәхет, шатлык, озын гомер телибез.

Халык күңелендә Сезгә дигән
Меңәрләгән чәчәк бәйләме
Әгәр аны алдыгызга куйсак
Булыр алар таулар кадәрле…
Кояшны да бүләк итәр идек
Кояш биек, ә без кечкенә
Чәчәктән дә матур, назлы бүләк
Тапмадык без бүген һич кенә…






*Бәйрәм белән Сезне, укытучым!*
*Йөрәгемнең якын кешесе.*
*Дөнья серен миңа өйрәтүчем.*
*Яшь җаннарга — Ходай илчесе!*

*Сезгә телим саулык, озын гомер,*
*Шәхси бәхет, дөнья рәхәтен.*
*Шәкертләрнең тырыш, инсафлысын.*
*Яхшы гамәл, Ходай рәхмәтен!*

# Укытучым - тормыш маягым



*Укытучы, мәктәп!*
*Бу ике сүз*
*Күңелемдә яши янәшә*
*"Мәктәбем", - дип дәшкән*
*чакта күңел,*
*"Укытучым!" – дип йөрәк эндәшә.*



*Кеше... Ул һәрвакыт төрле каршылыкларга юлыгып яши. Гомер юлында аларны җиңәргә өйрәнә, сыный-сынала. Сынау-сыналу чорында кеше, әлбәттә, тәҗрибә дә туплый, акылга да үсә, ныгый.*

*Көрәш кагыйдәсе буенча тормышта кемдер җиңә, ә кемдер җиңелә, кемдер онытыла, ә кемдер данга күмелә.Шулай итеп, адәм баласы бу тормышта үз юлын таба, олы бәхеткә ирешә. Ләкин ул, бәхеткә ирештем дип, үзенең дөньядагы иң зур байлыгын − кешелеклелек сыйфатларын югалтмаска тиеш.*

*Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен. Кеше үз-үзен хөрмәт итәргә тиеш.Чыннан да, кешелек дөньясы яратылганнан бирле, кеше үзе генә бер дөнья булып яши алмый. Аны чолгап алган мохит, аралашу, яшәү – болар барысы да кеше дөньясының үсешенә йогынты ясый. Шуңа күрә дә икенче берәүләр белән аралаша белү, үз-үзеңә карата таләпчәнлек булдыру, гаделлек, тыйнаклык, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатларны тәрбияләү, ихтирамлы һәм игътибарлы булу − болар барысы да Кеше дигән сүзне зур хәреф белән язарга мөмкинлек бирә.*

*Тормыш никадәр катлаулы булса да, кеше үз язмышына үзе, бары тик үзе генә хуҗа була ала. Яшәеше, эш-гамәле белән үзенең исемен акларга, гомер елларын барлаганда, тирән горурлык хисе тоярга тиеш ул. Әлеге юллар нәкъ менә безнең укытучыбыз турында. Ана исеме белән тиңләшердәй, синең өчен көенеп ут йотучы, синең өчен сөенүче, тормышта бар нәрсәне җиңеп алга барырга өйрәтүче, гомумән, кешелеккә лаеклы буын үстерү өчен, үзен аямыйча, эш һәм ял сәгатен санамыйча эшләүче кеше – ул мөгаллим*

*Бу дөньяда нинди генә биеклекләргә ирешсәк тә, уңышларыбыз башында укытучы торганын һәркем аңлый. Әйе, нәкъ менә алар кешелекне мәгърифәт дөньясына алып керә, хәреф танырга, язарга өйрәтә, белгәннәрен хәтергә сеңдерергә тырыша, тәрбияле булырга өнди*

*Менә шундый олуг мөгаллимнәрнең берсе Олы Елга гомуми белем бирү мәктәбе директоры Миннегалиева Гөлнур Мансуровна. Гөлнур Мансуровна - намуслы, тырыш хезмәте, сабырлыгы һәм гаделлеге белән укучылары, авыл халкы, хезмәттәшләре арасында да зур абруй казанган хөрмәтле укытучы. Ачык йөзле, шаян, кешелекле, чисталык һәм тәртип яратучы укытучым – укучыларның иң яраткан мөгаллимнәренең берсе.*

*Гөлнур апаның йөзеннән генә түгел, йөрәгеннән дә нур сирпелеп тора. Укыту өлкәсендә белмәгәне юк аның. Иртәдән кичкә кадәр белем йортында ул. Берәүне дә игътибарсыз калдырмый, һәммәсендә дә ярдәм итәргә вакыт таба. Компьютерны да биш бармагы кебек белә, мәгариф өлкәсендәге һәм илкүләм яңалыклар белән дә танышып бара, аларны безнең белән бик теләп уртаклаша. Укытучы булу өчен һөнәри белем, ә иң яхшы укытучы булыр өчен балаларны яратып, эшеңә күңел җылыңны салу кирәк. Директорыбыз – әнә шундыйлардан. Укытучы булу өчен һөнәри белем, ә иң яхшы укытучы булыр өчен балаларны яратып, эшеңә күңел җылыңны салу кирәк. Кайда гына булмасын, Гөлнур апа үзенең укытучы дигән горур исеменә тап төшерми. Ул – яшь буынга белем, тәрбия һәм киңәш бирүче.*

*Мин сезнең укучыгыз булуым белән горурланам. Сез безгә, канат яручы кошчыкларга, белем биреп кенә калмыйсыз, ә олы тормыш юлына да әзерлисез. Мең – мең рәхмәт сезгә!*



*Галиуллина Илүзә, 8 класс*

# Укытучым - якты кояшым




Лилия апа безгә бишенче сыйныфтан бирле табигать белеме һәм география фәннәрен укыта. Ул дәрестә безгә җирнең кайда, ничек урнашуы турында сөйли, андагы материкларны, океаннарны һәм андагы халыкларны аңлата. Мин Лилия апаның дәресен көтеп алам, анда вакытның ничек тиз үткәнен сизми дә калам, чөнки ул дәресләрне кызыклы, мавыктыргыч итеп үткәрә белә (Абдуллин Ильнур).

Әле бүгенгедәй хәтеремдә..Кояшлы матур 1 сентябрь иртәсендә Алсу Фоатовна безне елмаеп каршы алды. Шул көннән башлап үзара дус яшәргә, мәктәп елларын онытылмаслык итеп хәтерергә калдырырга, яхшы укырга өндәүче, матур сүзләр табып кәефебезне күтәрүче укытучым минем. Аның белән һәрвакыт серләшәсе, күңелдәгене сөйлисе, көлеп кенә торасы килә.. (Яфизова Алсинә, 5 класс).

Минзилә апа безне беренче сыйныфтан бирле укыта.Ул безгә үрнәк, терәк һәм таяныч. Безгә авыр чакта ул тынычландыра, елаган чакларда юата. Минзилә апа безнең матур, мәрхәмәтле, белемле һәм җылы йөрәкле..(Гильмутдинова Ләйлә,4 класс).

Безнең мәктәптә бик күп яхшы укытучылар эшли. Шуларның берсе тарих һәм татар теле укытучысы – Венера апа. Дәрестә утырганда, без Венера апаның авыр теманы аңлатуларын кызыксынып тыңлап утырабыз. Аның китерелгән мисаллары дәресне җиңелрәк үзләштерергә булыша. Венера апаның дәресендә үзеңне уңайлы һәм ышанычлы хис итәсең. Сыйныф җитәкчесе дэ булгач, Венера апа безгә аеруча якын. Ул һәрвакыт безне кайгыртып тора. Акыллы киңәшләрен бирә. Узенең сабырлыгы, тыйнаклыгы белән ул купләргә урнэк укытучы (Миннигалеев Радиф,9 класс).

Валиева Эльвира Ризвановна - инглиз теле укытучысы.Мин бик каты инглиз теле яратам. Мин бу дэрестэ 5-4лэр генэ алам.Элвира апа дэреслэрдэ бик эйбэт анлата. Анын дэреслэре бик кунелле утэ.Мин инглиз теле дэреслэренэ бик телэп йорим.Эльвира апа шат кунелле, ачык йозле, бик матур укытучыларнын берсе. Укытучыбыз барыбызга да бер торле караштa. Һэр кемне тигез курэ. Рэхмэт сина, укытучым, безгэ белем биргэн очен (Закиров Ильшат, 6 класс)

Физика дәресләрен мин бик яратам,чөнки бу дәресләрдә мин үзем өчен кызыклы информацияләр алам.Дәресләрдә Рушания Ильдусовна бар нәрсәне дә әйбәтләп аңлата.Аңламасак барысын да яңадан яхшылап аңлата. Рушания Ильдусовна һәр вакыт игелекле,гадел,игътибарлы, ягымлы һәм түземле кеше.. (Сибгатуллин Рифат, 7 класс)

# Яраткан укытучым

Авыр чакларда Алсу Фаридовна гел ярдәмгә килә, үзенең киңәшләре белән безне олы тормышка әзерли. Минемчә, иң мөһиме, Алсу апаның безнең белән тигез аралашуы, ул укучыларга дусларча якын мөнәсәбәттә, шуңа күрә аның белән курыкмыйча бар нәрсә турында да сөйләшергә, киңәшләшергә була. Мондый укытучылар булганда мәктәптә укуы - үзе бер рәхәт! (Айзилә Сибгатуллина, 11 класс)

Кадрия апа безнең сабый күңелләребезгә ачкыч таба белде. Ул йомшак күңелле, сабыр, тирән белемле һәм хөрмәткә лаек укытучы. Ул безнең белән бергә шатланды да, көенде дә, безне чын кешеләр итеп тәрбияләргә тырышты, намуслы, кешеләргә карата шәфкатьле, мәрхәмәтле булырга өйрәтте (Сибгатуллина Ләйсәнә, 9 класс)

Башлангыч сыйныфта укыган дүрт ел минем хәтеремдә һәрвакыт сакланачак. Нәйсә апаның ипләп кенә кулымнан тотып, якты сыйныфка алып керуе...Дәресләрне дә аңлаешлы һәм күңелле үткәрүе. Ул белемле, таләпчән, сабыр,гадел укытучы (Миннегалиева Алинә, 9 класс).

Сердәшчебез, киңәшчебез , икенче әниебез булган Сәвия апаны без беркайчан да онытмабыз. Аның исеме безнең йөрәк түрендә! Барысы өчен дә рәхмәт сезгә укытучыбыз, мең рәхмәт! Рухыбызга иман салдыгыз, барабызны да тигез күреп , балагыздай каршы алдыгыз. Бәйрәмегез котлы булсын! (Салахова Энже, 11 класс)

Гөлфия апа һәм Гөлфәния апа безне яраталар һәм безнең әйбәт булуыбызны телиләр. Безнең уңышларга сөенәләр, кайгыларыбызны уртаклашалар. Дәресләрне дә аңлаешлы һәм күңелле итеп үткәрә алар. Аңламаган темаларны кат – кат аңлатырга да вакытын кызганмыйлар. Аларның белмәгән нәрсәсе юк, бөтен сорауларга җавап табалар (Вахитова Чулпан, 7 класс).

Рушания апада 4 ел укып, мин аның турында күп әйбер белергә өлгердем. Беренчедән, Рушания апа бик яхшы һәм кайгыртучан. Ул безне гел яхшылыкка гына өйрәтә, тәртипле булуыбызны тели. Һәрвакыт безгә нәрсәне эшләргә ярый, нәрсәне ярамый икәнлекне әйтә. Безнең класста еш кына дисциплина сәгатьләре үткәрелә. Рушания апаны безнең икенче әниебез дип әйтеп була. Әниләребез кебек үк, ул да безне кирәк вакытта мактый, ә кайчак ачулана да белә. Ләкин без аңа үпкәләмибез, ә киресенчә, хатабызны төзәтергә һәм апа әйткәнчә эшләргә тырышабыз. Әйткәнемчә, апабыз бик кайгыртучан. Ул һәрвакыт безнең өчен кайгыра. Берәребез авырып китсә, аның күңеле тыныч түгел. Безне тизрәк терелтер өчен: «Сиңа моны эшләргә ярамый, син мондый дару эч»,- дип киңәшләр бирә. Ә инде киңешләре безгә файда китерсә, ул бик нык сөенә (Камалова Эльвира)

Минем дә яраткан укытучым бар. Ул-татар теле укытучысы . Мин аның мавыктыргыч дәресләрен көтеп алам. Гади дә,аңлаешлы да , тирән эчтәлекле дә ул дәресләр һәр теманы тормыш белән бәйләп анлатуы миңа бик ошый .Ул бик әйбәт укытучы. Гадел һәм туземле ,тыныч һәм ягымлы . Безне ярата һәм безнең әйбәт укуыбызны тели . Дәресләрне дә бик куңелле итеп уткәрә ул. Аңламаган темаларны кат-кат аңлатырга да вакытын кызганмый. Аның белмәгән нәрсәсе юк , бөтен сорауларга да җавап таба.
Укытучым менә шундый оста һөнәр иясе икән ул! Бик зур рәхмәт сезгә , Әльфинур апа! Без сезне яратабыз! ( Сибгатуллина Гөлсәрия, 7 класс)

Безнең мәктәбебездә иң яхшы укытучылар эшлиләр. Биология һәм химия укытучысы- Иванова Әлфия Минхафизовна аларнын берсе булып тора.Ул һәрвакыт гадел, игьтибарлы һәм ярдәмчел кеше. Ул һәр укучының үзенчәлекләренә игътибар итеп укыта, авыр вакытларда ярдәм кулын суза һәм югары үрләргә үрмәләргә рухландыра белә. Безнең олимпиадаларда катнашып, урыннар яулавыбыз-аның тугрылыклы хезмәтенең нәтиҗәсе (Сафиуллина Алсинә, 11 класс)

# Һөнәр сайлый башладым

Менә мин дә тугызынчы сыйныфка җиттем. Акыл туплый,һөнәр сайлый торган чор. Бик авыр вакыт икән бу! Җир шарында һөнәрләр күп... Сайлый башлагач, кайсына сабырлык җитеп бетми, кайсына белем, кайсына ялкаулык комачаулый кебек.Эх!!!!!Шулай баш ватып йөргән көннәрнең берендә...Физкультура дәресе. Сәгыйть абый, смерно бастырып, тәртип оештыра. Карап-карап тордым да, башка акыллы фикер килеп төште. Ә нишләп физкультура укытучысы булмаска соң әле.Сыбызгысын бер генә сызгырта, күз ачып йомганчы, бөтен мәктәп үрә ката. Китап укытып, шигырь ятлатып, контроль эш,тестлар эшләтеп тә балалар башын катырмый, үзенә дә бик җайлы, чүмәлә-чүмәлә дәфтәрләргә чумып ятмый. Шәп һөнәр бу! Моны сайласам,Сәгыйть абыйныкы кебек йөземнән елмаю мәңге китәчәге юк, сәламәтлегем дә какшамас. Шулар турында уйлап, үзе белән киңәшим, серләшим, дип янына кереп барганда...Китап-дәфтәрләргә чумган, электрон журнал тутыручы Сәгыйть абыйга тап булдым. Ой... Бу эшләр физкультура укытучысын да читләтеп үтми икән бит! Кара син ә...Документ эшенә чумган Сәгыйть абыйны бөтенләй танып булмый.Сәгыйть абый түгел, Сәгыйть Сахабутдинович дип кенә дәшәсе килә.Бөтен уйларым чуалды. Укытучы эше кайсы гына кабинетка керсәң дә, кайсы гына предметны алсаң да, шул икән инде ул. Болай булгач, яңа һөнәр сайламый булмас... Ә Сезгә укытучыларым, катлаулы эшегезне елмаю астына яшереп, безгә төпле белем биргәнегез өчен ЗУР РӘХМӘТ!!! (Фәхретдинов Фәннур, 9 класс)

Укытучы булып бары тик югары белемле,үз эшен яратучы,балаларны аңлаучы,сабыр,зур тәҗрибәле кеше генә эшли ала. Илнур абыйда бу сыйфатлар барысы да бар.Математика фәне бик катлаулы булуына карамастан,һәр укучы аның дәресләрен туземсезлек белән көтеп ала. Ул һәр теманы тырышып,көчен кызганмыйча,җентекләп аңлата. Авыррак үзләштерелгән темаларны Илнур абый кат-кат аңлатырга да вакытын кызганмый.Илнур абый йомшак күңелле дә,кирәк вакытта кырыс та була белә. Алай гына да түгел ул бик яхшы сыйныф җитәкчесе дә.Ул һәрберебезне игътибар белән тыңлый,булдыра алганча ярдәм итә.

Риф абый– сабыр, булдыклы, уңган, бик күпләргә үрнәк булырлык шәхес. Күп санлы мактау сүзләре – аның тынгысыз хезмәте нәтиҗәсе. Наил абый-ярдәмчел, шәфкатьле, чын ир-егет өлгесе. Анын дәресендә бу тормышта кирәкле бик күп мәгълүмат аласың. Аларның һәр дәресе онытылмаслык булып үтә..

Илнур абый, Риф абый, Наиль абый – сез чын мөгаллимнәр
Укытуда сезгә тиңнәр юк
Тапкырлыгыгыз,зирәклегегез белән
Безгә һәрчак үрнәк сез . (Абдуллина Ләйсән).